ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423750, Уразай авылы, Узэк ур., 2 нче йорт. Тел 3-44-62
Email: : uraz-akt-2@yandex.ru

УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423750, дер.Уразаево, ул. Центральная , дом 4. Тел 3-44-62
Email: uraz-akt-2@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«25» апрель 2025 ел №7

Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 16.03.2020 ел, № 6 (28.02.2025 ел № 3 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай_ авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.03.2020 ел, № 6 (28.02.2025 ел № 3 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Уразай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктыннан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:
"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип танылa торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".
1.2. 3.9_1 пунктын төшереп калдырырга.
1.3. 3.10_1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.10_1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.»
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Шаймарданова Г.С.